**Татарстан Республикасы Кама Тамагы муниципаль районы Яңасала авыл җирлеге Шәпкә авылында гражданнардан 2026 елда үзара салым кертү турында**

**КАРАРы**

**26 нче ноябрь 2025 ел** **№ 3**

«Гавами хакимиятнең бердәм системасында җирле үзидарәне оештыруның гомуми принциплары турында» 2005 елның 20 мартындагы 33-ФЗ номерлы Федераль законның 45, 69 статьялары нигезендә, “Татарстан Рес публикасында җирле узидарә турында” 2004 елнын 28 июлендәге 45-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законының 35 статьясы нигезендә Татарстан Республикасы Кама Тамагы муниципаль районының Шәпкә авылында гражданнар җыены **карар итте**:

1.Үзара салым 2026 елда Татарстан Республикасы Кама Тамагы муниципаль районының Шәпкә авылы территорясендә яшәү урыны буенча теркәлгән һәр балигъ булган кешедән 1000(Бер мең) сум күләмендә кертергә.

2. Алынган акчаларны җирле әһәмияттәге мәсьәләләрне хәл итүгә түбәндәгеләрне үтәү буенча юнәлтергә:

**- торак пункт чикләрендә гомуми файдаланудагы җирле әһәмияттәге автомобиль юлларын төзү, ремонтлау, карап тоту;**
**- янгын куркынычсызлыгының беренчел чараларын тәэмин итү;**
**- торак пунктның башка территорияләрен төзекләндерү;**
**-- җир асты суларының табигый чыгу урыннарын төзекләндерү (чишмәләр).**

3. Әлеге карарны түбәндәге адреслар буенча урнашкан мәгълүмат стендларына урнаштырып халыкка җиткерү:

- ТР Кама Тамагы районы Олы Яңасала авылы Үзәк ур., 1;
- ТР Кама Тамагы районы Шәпкә авылы,Клуб урамы, 14 йорт, шулай ук Татарстан Республикасы хокукый мәгълүмат рәсми сайтында бастырып чыгарырга һәм Татарстан Республикасы Кама Тамагы муниципаль районының рәсми сайтында урнаштырырга.

Халык җыенында рәислек итүче ,
Татарстан Республикасы Кама
Тамагы муниципаль районы
Яңасала авыл җирлеге
башлыгы: И.Х.Шиһабеев